РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 31 » 08 2020г. №658

2020 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыру турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.08. 2020 ел №728 «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында" 28.08.2019 ел, № 724 «Мәгарифне үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июнендәге 990 номерлы РФ Хөкүмәте Карарына теркәлгән кушымтага үзгәрешләр кертү турында” Карарына ярашлы һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларның туклануын оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар кабул итә:

1. 2020 елның 1 сентябреннән расларга:

-Урыссу шәһәр тибындагы поселогының гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныфларда укыган бер укучысына - 45 сум 70 тиен күләмендә туклану бәясен, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга бер көнгә 7 сум 70 тиен күләмендә субсидияләрне,
- уку чорында бер укучыга бер көнгә 38 сум 00 тиен күләмендә ата-аналар взносы суммасын;
- авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныфларда белем алучы бер укучыга көнгә - 42 сум 70 тиен күләмендә туклану бәясен, шул исәптән:
- уку чорында бер укучыга бер көнгә 7 сум 70 тиен күләмендә субсидияләрне;
- уку чорында бер укучыга бер көнгә 35 сум 00 тиен күләмендә ата-аналар взнослары суммасын.

2.Түбәндәге категориядәге укучыларны бушлай бер тапкыр кайнар аш белән тәэмин итәргә:

- башлангыч гомуми белем алучы балаларны;

- 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә балаларын. Өч һәм аннан да күбрәк бала гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алса, әлеге категориядәге укучыларга ташламалы туклану тәэмин ителә;

- әти-әниләре 1 һәм 2 нче группа инвалид булган балалар.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы, муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыру чыгымнарын «Мәгариф» тармагы буенча 2020 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тиеш.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" **http://pravo.tatarstan.ru** веб-адресы һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә **http://jutaza.tatarstan.ru** веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С. П. Самонина

Г. М. Гыйләҗева
2-71-00